| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>Ул.Центральная, д.46, с.Бизяки, Менделеевский район, Республика Татарстан, 423648 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ<br>Үзәк урам, 46 йорт, Бәзәкә авылы, Менделеевск районы, Татарстан Республикасы,423648 |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 3 10.11.2025 ел

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 21 ноябре 13.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздырырга. Гражданнар җыены уздыру урыны итеп Сәйтәк авылы, Дуслык урамы, 10А йорт адресы буенча урнашкан Сәйтәк авыл мәдәният йортын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:

"2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан Сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән 50%ка киметеп 500 сум күләмендә, ә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?":

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;( Сәйтәк авылындагы юлларны кардан чистарту вак таш, асфальт валчыклары сатып алу, Сәйтәк авылында юлларны тигезләү,).

2. Су белән тәэмин итү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (суга батыру насослары сатып алу).

3. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чабу)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru "Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы _______ И.И. Кәшәфетдинов
(имза) (имзаны киңәйтү)